**Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы**

**Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты**

# КАРАР

№ 95 04.12.2019 ел.

Аграмак авыл җирлегендә пиротехник эшләнмәләр
куллану мәйданчыкларын билгеләү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, "янгын куркынычсызлыгы турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, "янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент" 2008 елның 22 июлендәге 123 - ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы «пиротехник эшләнмәләр кулланган очракларда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» карары нигезендә, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне саклау максатларында Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты

Карары:

1. Аграмак авыл җирлеге халкы һәм кунаклары өчен фейерверклар үткәрү, пиротехник продукция куллану мәйданчыкларын билгеләргә:
1.1. Аграмак авылында-Аграмак төп мәктәбе территориясе, Мәктәп урамы тәмамланганнан 500 м ераклыкта;
1.2. Татар Такталы авылы-Тахтала елгасы ярында урнашкан территория, үзәк урамнан 500 м ераклыкта.
2. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтының (http / www. spasskiy.tatarstan.ru) Аграмак авыл җирлеге битендә, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (///http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән срокта бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Спас
муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге
Башкарма комитете җитәкчесе: Р. Т. Галәветдинова

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ